***ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***
***ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ***

**К А Р А Р № 16**

**Кече Урыссу ав.** **25 август 2023ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Советының 2009 елның 3 июнендәге 8 санлы карары белән расланган «Ташкичү авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм аның белән эш итү тәртибе турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2023 елның 14 апрелендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 129-ФЗ санлы Федераль закон, 2018 елның 3 июлендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 68 статьясына үзгәреш кертү хакында»гы 189-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Ютазы муниципаль районының «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ташкичү авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге советының 2009 елның 3 июнендәге 8 санлы карары белән расланган «Ташкичү авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм аның белән эш итү тәртибе турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.10 пунктындагы 17 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17) «Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда аларның тарихи-мәдәни әһәмияте категориясенә бәйсез рәвештә Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда мәдәни мирас объектлары (алга таба - мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре).»;

Нигезләмәнең 5.4 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) коммерциягә карамаган автоном оешмалар һәм фондлар рәвешендә коммерциягә карамаган оешмалар төзү турында гавами булмаган акционер җәмгыятьләр һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр рәвешендә муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре оештыру турында Ташкичү авыл җирлеге Советы каравына карарлар кертү

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә

органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К. Вәлеев